# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 28.03.2024 г.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә , «Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 18 мартындагы 2 номерлы карары нигезендә 2024 елның 28 мартында 17.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән сораулар буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) традицион күмү урыннарынтөзекләндерү (койма тоту)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган _13__ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - __8__ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен __8__катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен ____0___ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл жирлегенең Яңа Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп :

1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү (койма тоту)

«Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1 нче номерлы, «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 7

ноябрендәге 2 нче номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Саклаубаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина